БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2019 ел Баулы шәһәре № 105

Баулы шәһәр Советының
2014 елның 11 ноябрендә
кабул ителгән «Җир салымы
турында»гы 114нче номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32нче бүлеге нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2014 елның 11 ноябрендә кабул ителгән «Җир салымы турында»гы 114нче номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2016 елның 28 сентябрендәге 43нче, 2017 елның 15 июнендәге 53нче, 2017 елның 25 октябрендәге 61нче, 2017 елның 15 декабрендәге 67нче, 2018 елның 16 ноябрендәге 92нче, 2018 13 декабрендәге 97нче каралары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге пунктчалар белән тулыландырырга:

«7) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган яки 23 яшькә кадәрге көндезге уку формасында укучы балалары булган гражданнар».

2. Салым ташламасы бер җир участогына ата-аналарның берсенә (җир участогы теркәлгәненә) яки, ташлама бирелгән җир участогы өлешле милек булганда, ике ата-анага һәм балаларга бирелә.

3. Салым ташламасы Баулы шәһәре территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә аның милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлегенә карата салым суммасы күләмендә бирелә.

4. Салым түләүче салым органына мөрәҗәгатен салым чоры булып исәпләнгән һәм җир участогына карата салым ташламасы кулланыла башлаган елның 1 ноябренә кадәр тапшыра.

5. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин аны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгарган көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

Әлеге карар 2019 елдан башлап җир салымын исәпләү тәртибенә карата гамәлдә.

6. Баулы шәһәр Советының «2014 елның 11 ноябрендә кабул ителгән 114нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 13 декабрендә кабул ителгән 97нче номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталда бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы рәисе

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин